**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 22 июль № 495

г. Казань

Техник паспортларны, 2013 елның 1 гыйнвары хәленә карата дәүләт техник исәпкә алу һәм (яки) техник инвентарьлаштыру органнарында һәм оешмаларында сакланган бәяләү документларын һәм дәүләт техник исәпкә алу һәм техник инвентарьлаштыру объектлары турындагы башка исәпкә алу-техник документларны даими саклауга тапшыру тәртибен раслау хакында

«Күчемсез мөлкәт дәүләт кадастры турында» 2007 ел, 24 июль, ФЗ-221 нче Федераль законның 45 статьясындагы $2^4$ өлешен тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Техник паспортларны, 2013 елның 1 гыйнвары хәленә карата дәүләт техник исәпкә алу һәм (яки) техник инвентарьлаштыру органнарында һәм оешмаларында сакланган бәяләү документларын һәм дәүләт техник исәпкә алу һәм техник инвентарьлаштыру объектлары турындагы башка исәпкә алу-техник документларны даими саклауга тапшыру тәртибен расларга.

2. Техник паспортларны, 2013 елның 1 гыйнвары хәленә карата дәүләт техник исәпкә алу һәм (яки) техник инвентарьлаштыру органнарында һәм оешмаларында сакланган бәяләү документларын һәм дәүләт техник исәпкә алу һәм техник инвентарьлаштыру объектлары турындагы башка исәпкә алу-техник документларны (алга таба – техник документлар) Татарстан Республикасы территориясендә түләүсез нигездә даими саклауны гамәлгә ашыра торган оешма сыйфатында Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Техник инвентарьлаштыру бюросы» республика дәүләт унитар предприятиесен (алга таба – Техник инвентарьлаштыру бюросы) билгеләргә.

3. Техник инвентарьлаштыру бюросы «Ростехинвентаризация – Федераль ТИБ» федераль дәүләт унитар предприятиесе, «Җир» кадастр үзәге» муниципаль унитар предприятиесе белән берлектә:

2016 елның 30 июленә кадәр Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белән техник документларга инвентарьлаштыру үткәрергә;

2016 елның 1 сентябренә кадәр Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына техник документларны кабул итү-тапшыру акты буенча бирергә.

4. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына 2016 елның 1 октябреннән дә соңга калмыйча Техник инвентарьлаштыру бюросы белән техник документларны саклау шартнамәсе төзергә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2016\495.docx

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 22 июль, 495 нче карары белән расланды

Техник паспортларны, 2013 елның 1 гыйнвары хәленә карата дәүләт техник исәпкә алу һәм (яки) техник инвентарьлаштыру органнарында һәм оешмаларында сакланган бәяләү документларын һәм дәүләт техник исәпкә алу һәм техник инвентарьлаштыру объектлары турындагы башка исәпкә алу-техник документларны даими саклауга тапшыру тәртибе

1. Әлеге Техник паспортларны, 2013 елның 1 гыйнвары хәленә карата дәүләт техник исәпкә алу һәм (яки) техник инвентарьлаштыру органнарында һәм оешмаларында сакланган бәяләү документларын һәм дәүләт техник исәпкә алу һәм техник инвентарьлаштыру объектлары турындагы башка исәпкә алу-техник документларны даими саклауга тапшыру тәртибе «Күчемсез мөлкәт дәүләт кадастры турында» 2007 ел, 24 июль, ФЗ-221 нче Федераль закон нигезендә эшләнде һәм дәүләт техник исәпкә алу һәм (яки) техник инвентарьлаштыру органнары һәм оешмалары (алга таба – техник инвентарьлаштыру оешмалары) тарафыннан техник паспортларны, 2013 елның 1 гыйнвары хәленә карата дәүләт техник исәпкә алу һәм (яки) техник инвентарьлаштыру органнарында һәм оешмаларында сакланган бәяләү документларын һәм дәүләт техник исәпкә алу һәм техник инвентарьлаштыру объектлары турындагы башка исәпкә алу-техник документларны (алга таба – техник документлар) Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Техник инвентарьлаштыру бюросы» республика дәүләт унитар предприятиесенә (алга таба – Техник инвентарьлаштыру бюросы) түләүсез даими саклауга тапшыру процедурасын билгели.

2. Техник документларны түләүсез даими саклауга тапшыру Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы һәм Техник инвентарьлаштыру бюросы тарафыннан төзелә торган саклау шартнамәсе нигезендә 2016 елның 1 октябреннән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

3. Техник инвентарьлаштыру оешмалары Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белән берлектә түләүсез даими саклауга тапшырылырга тиешле техник документларга инвентарьлаштыру үткәрә.

4. Техник документлар Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына техник инвентарьлаштыру оешмалары тарафыннан – әлеге Тәртипкә теркәлгән 1 нче кушымтада китерелгән формага ярашлы рәвештә төзелгән кабул итү-тапшыру акты буенча, Техник инвентарьлаштыру бюросы тарафыннан әлеге Тәртипкә теркәлгән 2 нче кушымтада күрсәтелгән формага ярашлы рәвештә төзелгән кабул итү-тапшыру акты буенча бирелә. Техник документларны кабул итү-тапшыру акты тигез юридик көчкә ия ике нөсхәдә төзелә.

5. Техник документлар түләүсез даими саклауга аларга тапшырылган инвентарь саннары нигезендә тәртипкә китерелгән хәлдә бирелә.

6. Техник документларны Техник инвентарьлаштыру бюросына түләүсез даими саклауга тапшыру техник инвентарьлаштыру оешмалары белән килештерү

буенча Техник инвентарьлаштыру бюросы җитәкчесе раслаган план нигезендә гамәлгә ашырыла. Техник документлар Техник инвентарьлаштыру бюросының техник документлар тутырылган объект урнашкан урын буенча муниципаль берәмлектә (муниципаль районда, шәһәр округында, республика карамагындагы шәһәр нигезендә оештырылган шәһәр җирлегендә) булган структур бүлекчәсенә тапшырыла.

7. Техник инвентарьлаштыру бюросына техник документларны тапшыру әлеге Тәртипкә теркәлгән 3 нче кушымтада күрсәтелгән форма буенча һәр тапшыру датасына төзелгән исемлек нигезендә гамәлгә ашырыла. Бер муниципаль берәмлектә (муниципаль районда, шәһәр округында, республика карамагындагы шәһәр нигезендә оештырылган шәһәр җирлегендә) урнашкан объектларга аерым исемлек төзелә. Исемлек өч нөсхәдә кәгазьдә, шулай ук электрон рәвештә төзелә. Электрон рәвештә төзелгән исемлеккә документларны тапшыра торган оешма вәкаләтле затының квалификацияле электрон имзасы куела.

8. Техник инвентарьлаштыру оешмалары, Техник инвентарьлаштыру бюросы вәкиле белән берлектә, техник документларны түләүсез даими саклауга тапшырыр алдыннан инвентарь эшләрен язып алу һәм рәсмиләштерү дөреслегенә, техник документларның физик һәм санитария-гигиена хәленә тикшерү үткәрә. Кимчелекләр табылган очракта акт төзелә.

9. Техник инвентарьлаштыру бюросына инвентарь эшләрен тапшыру берәмлекләп башкарыла. Берәмлек булып (тапшыру һәм алга таба саклау максатларында) инвентарь эше санала. Инвентарь эшләреннән тыш, әлеге Тәртипкә теркәлгән 4 нче кушымтада күрсәтелгән форма буенча аерым исемлек төзелә торган инвентарь кенәгәләре дә бирелергә тиеш.

10. Техник инвентарьлаштыру оешмалары техник документлар составында тапшырыла торган техник паспортларның график өлешен Техник инвентарьлаштыру бюросына шулай ук электрон рәвештә DWG яки DXF форматында бирә. Техник документлар составында тапшырыла торган техник паспортларның график өлешен бирү электрон мәгълүмат саклау җайланмасында гамәлгә ашырыла һәм исемлектә күрсәтелергә тиеш.

11. Әгәр саклаганда инвентарь эше составында документ булмавы ачыкланса (аны техник инвентарьлаштыру оешмалары тутырганны раслый торган шартлар булганда), әлеге документлар сорату килгән көннән соң биш көн эчендә техник инвентарьлаштыру оешмалары тарафыннан Техник инвентарьлаштыру бюросына даими саклауга тапшырыла.

---

Техник паспортларны, 2013 елның 1 гыйнвары хәленә карата дәүләт техник исәпкә алу һәм (яки) техник инвентарьлаштыру органнарында һәм оешмаларында сакланган бәяләү документларын һәм дәүләт техник исәпкә алу һәм техник инвентарьлаштыру объектлары турындагы башка исәпкә алу-техник документларны даими саклауга тапшыру тәртибенә 1 нче кушымта

Форма

**Техник документларны саклауга кабул итү-тапшыру**
**АКТЫ**

______________________________________________________________________________
(документларны тапшыру нигезе)

______________________________________________________________________________
(документларны тапшыра торган оешма исеме)

түбәндәге техник документларны тапшырды, ә ____________________________________ ________________________йөзендә Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы, _____________________________________________ йөзендә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Техник инвентарьлаштыру бюросы» республика дәүләт унитар предприятиесе (алга таба – ТИБ РДУП) катнашында кабул итте:

| Т/с | Исемлекнең саны һәм датасы | Саклау берәмлекләре һәм томнар саны | Искәрмәләр |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| | | | |

Барлыгы ___________________________________________ саклау берәмлеге кабул ителде.

Барлыгы электрон рәвештә ______ (файлның форматы) форматында ______ Мб күләмдә _______ берәмлек кабул ителде.

Электрон мәгълүмат саклау җайланмалары саны – _____________________________ данә.
(сүзләр белән күрсәтелә)

Кушымта:
Даими саклауга тапшырыла торган техник документлар исемлеге – ____ данә.

Тапшыруны башкардылар:

Вазыйфа
Имза
Имзаның аңлатмасы
М.У. (булган очракта)

Кабул итүне башкардылар:

Вазыйфа
Имза
Имзаның аңлатмасы
М.У. (булган очракта)

Тикшерүне башкарды:

ТИБ РДУПдә вазыйфасы
Имза
Имзаның аңлатмасы
М.У. (булган очракта)

Техник паспортларны, 2013 елның 1 гыйнвары хәленә карата дәүләт техник исәпкә алу һәм (яки) техник инвентарьлаштыру органнарында һәм оешмаларында сакланган бәяләү документларын һәм дәүләт техник исәпкә алу һәм техник инвентарьлаштыру объектлары турындагы башка исәпкә алу-техник документларны даими саклауга тапшыру тәртибенә 2 нче кушымта

Форма

**Техник документларны саклауга кабул итү-тапшыру АКТЫ**

______________________________________________________________________________

(документларны тапшыру нигезе)

______________________________________________________________________________

(документларны тапшыра торган оешма исеме)

түбәндәге техник документларны тапшырды, ә ____________________________________

(документларны кабул итә торган оешма исеме)

______________________________________________ кабул итте:

| Т/с | Саклау берәмлеге исеме | Саны | Искәрмә |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| | | | |

Барлыгы __________________________________________ саклау берәмлеге кабул ителде.

(сүзләр белән күрсәтелә)

Тапшыруны башкардылар:

Вазыйфа
Имза
Имзаның аңлатмасы
М.У. (булган очракта)

Кабул итүне башкардылар:

Вазыйфа
Имза
Имзаның аңлатмасы
М.У. (булган очракта)

Техник паспортларны, 2013 елның 1 гыйнвары хәленә карата дәүләт техник исәпкә алу һәм (яки) техник инвентарьлаштыру органнарында һәм оешмаларында сакланган бәяләү документларын һәм дәүләт техник исәпкә алу һәм техник инвентарьлаштыру объектлары турындагы башка исәпкә алу-техник документларны даими саклауга тапшыру тәртибенә 3 нче кушымта

Форма

___________________________________________________________________________
(муниципаль район, шәһәр округы, республика карамагындагы шәһәр нигезендә оештырылган шәһәр җирлеге исеме)

_____________________________________________ муниципаль берәмлеге буенча исемлек

**_______ даими саклауга тапшырыла торган техник документлар**
**ИСЕМЛЕГЕ**

| Т/с | Инвентарь саны | Инвентарь кенәгәсе исеме[1] | Адрес | Соңгы инвентарь-лаштыру көне | Битләр/ томнар саны | Электрон версия булу/булмау | Искәрмә[2] |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| | | | | | | | |

Әлеге исемлек ______________________ төзелде.
(төзелгән көне)

Исемлек буенча инвентарь эшләре саны – _________________ данә.

Исемлекне төзүче, вазыйфасы _____________/_________________
(имзасы) (имзаның аңлатмасы)

Оешма җитәкчесе __________________/__________________
(имзасы) (имзаның аңлатмасы)

М.У. (булган очракта)

Исемлекне кабул итте һәм тикшерде:

Вәкаләтле зат, вазыйфасы _____________/__________________
(имзасы) (имзаның аңлатмасы)

М.У. (булган очракта)

______________________
[1]Инвентарь эше төзелгән объект исеме күрсәтелә.
[2]Өстәмә мәгълүмат күрсәтелә (документлар торышы, текстларының тулылыгы һ.б. турында).

Техник паспортларны, 2013 елның 1 гыйнвары хәленә карата дәүләт техник исәпкә алу һәм (яки) техник инвентарьлаштыру органнарында һәм оешмаларында саклаган бәяләү документларын һәм дәүләт техник исәпкә алу һәм техник инвентарьлаштыру объектлары турындагы башка исәпкә алу-техник документларны даими саклауга тапшыру тәртибенә 4 нче кушымта

Форма

**_______ даими саклауга тапшырыла торган инвентарь кенәгәләре**
**ИСЕМЛЕГЕ**

| Т/с | Инвентарь кенәгәсе исеме[1] | Соңгы даталар | Битләр саны | Искәрмә[2] |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| | | | | |

Әлеге исемлек ________________________ төзелде.
(төзелгән көне)

Исемлек буенча инвентарь кенәгәләре саны – __________________ данә.

Исемлекне төзүче, вазыйфасы ______________/__________________
(имзасы) (имзаның аңлатмасы)

Оешма җитәкчесе ___________________/__________________
(имзасы) (имзаның аңлатмасы)

М.У. (булган очракта)

Исемлекне кабул итте һәм тикшерде:

Вәкаләтле зат, вазыйфасы ______________/_____________________
(имзасы) (имзаның аңлатмасы)

М.У. (булган очракта)

[1] Кенәгә ачылган турында мәгълүмат, инвентарь эшләренең соңгы саннары күрсәтелә.
[2] Өстәмә мәгълүмат күрсәтелә (документлар торышы, текстларының тулылыгы һ.б. турында).